**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 18 июнендәге 2087 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2019 елның 12 февралендәге 515 номерлы «Кыска вакытлы арендага бирелә торган транспорт чараларын ташламалы урнаштыруга парковка рөхсәтен, кыска вакытлы арендага бирелә торган транспорт чарасын ташламалы урнаштыруга парковка рөхсәте турында язманы, кыска вакытлы арендага бирелә торган транспорт чарасын ташламалы урнаштыруга парковка рөхсәте турында язманың үзгәрүе һәм кыска вакытлы арендага бирелә торган транспорт чарасын ташламалы урнаштыруга парковка рөхсәтенең гамәлдән чыгуы хакындагы мәгълүматларны Казан шәһәре реестрына кертү буенча Казан шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Автомобильләрне кыска вакытка арендалау сервисын үстерү проектын гамәлгә ашыру максатыннан, 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы федераль законга туры китереп, Казан шәһәренең Контроль-хисап палатасы тәкъдимнәре нигезендә:

1. **Карар бирәм**:

1.1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2019 елның 12 февралендәге 515 номерлы «Кыска вакытлы арендага бирелә торган транспорт чараларын ташламалы урнаштыруга парковка рөхсәтен, кыска вакытлы арендага бирелә торган транспорт чарасын ташламалы урнаштыруга парковка рөхсәте турында язманы, кыска вакытлы арендага бирелә торган транспорт чарасын ташламалы урнаштыруга парковка рөхсәте турында язманың үзгәрүе һәм кыска вакытлы арендага бирелә торган транспорт чарасын ташламалы урнаштыруга парковка рөхсәтенең гамәлдән чыгуы хакындагы мәгълүматларны Казан шәһәре

реестрына кертү буенча Казан шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2019 елның 13 маендагы 1707 номерлы, 2020 елның 8 декабрендәге 3630 номерлы, 2021 елның 30 декабрендәге 3530 номерлы, 2024 елның 19 июлендәге 3024 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.1. 2.1 пунктта «10890 сум» сүзләрен «14345 сум» сүзләренә алмаштырырга;

1.1.2. 4.2 пунктчаның дүртенче абзацында «биш ел» сүзләрен «алты ел» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

2. Казан шәһәре Думасы аппаратының Мәгълүмат-аналитика идарәсенә (В.А.Казанцев) хезмәт күрсәтү стандартларына таләпләр үзгәрү турында массакүләм мәгълүмат чаралары, социаль медиаресурслар аша юл хәрәкәтендә катнашучыларга хәбәр итәргә **тәкъдим итәм**.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка **йөклим**.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**